ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 28.06.2024

**К А Р А Р** № 602

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 827 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 827 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 1 бүлегенең 1.5 пунктындагы 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортта бинаны яңадан планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән, һәм (яисә) яңа биналар барлыкка килүдән, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планировкасын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин